| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 май г.Казань № 501

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 август, 610 нчы; 2015 ел, 5 ноябрь, 837 нче; 2015 ел, 5 декабрь, 921 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 673 нче; 2017 ел, 21 февраль, 104 нче; 2017 ел, 24 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 431 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1051 нче; 2018 ел, 3 октябрь, 899 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1325 нче; 2019 ел, 6 июнь, 473 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2020 ел, 29 август, 758 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1201 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасына (алга таба – Ярдәмче программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ярдәмче программа паспортының «Ярдәмче программаның бурычлары» юлындагы 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Россия Федерациясе Музей фонды торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

Ярдәмче программаның II бүлегендәге җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Россия Федерациясе Музей фонды торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).»;

Ярдәмче программаның кушымтасында:

«5 нче бурыч. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 нче бурыч. Россия Федерациясе Музей фонды торышына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

5 нче бурычның 1 графасындагы «Татарстан Республикасы музейларында һәм музей-тыюлыкларында контроль чаралар үткәрү» юлында «контроль» сүзен «контроль (күзәтчелек)» сүзләренә алмаштырырга;

«5 нче бурыч. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле» юлының 4 графасындагы «Нәтиҗәләре гамәлдә түгел дип танылган тикшерүләр өлеше (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроленә карата)» өстәмә юлында «дәүләт контроле» сүзләрен «төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

«5 нче бурыч. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле» юлының 4 графасындагы «Административ җәзаларның гомуми санында кисәтүләр өлеше (Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроленә карата)» өстәмә юлында «дәүләт контроле» сүзләрен «төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин